Совет Старочукалинского
сельского поселения Дрож-
жановского муниципального
района Республики Татарстан

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районы Иске Чокалы
авыл җирлеге Советы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1061672003876 ИНН 1617003290

==================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

06 июнь 2022 ел № 17/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр, мәгълүматлар тапшыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 01.04.2002 ел, № 90-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр, мәгълүматлар тапшыру хакындагы 2015 елның 22 мартындагы 50/2 номерлы карары (26.10.2018 елдагы 38/3 номерлы үзгәрешләр белән) расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) **6 пунктның «в» пунктчасын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

в) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), санлы финанс активлары, аның хатыны (ире) һәм (яки) балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшыру елыннан

(алга таба - хисап чорында) календарь ел дәвамында, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми керемennән артып китсә, соңгы өч ел эчендә һәм әлеге алыш-бирешләр башкарылган акчалар алу чыганаклары турында.

2) **13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

“13. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып киткән очракта, әлеге алыш-бирешләрнең гомуми суммасы Чүпрәле муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтындагы авыл җирлеге бүлегендә “ http://drogganoye.tatarstan.ru/” законнар белән билгеләнгән тәртиптә, ә бу мәгълүматлар булмаган очракта, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә «Интернет» челтәрендә массакүләм мәгълүмат чараларына аларның сораулары буенча бастырып чыгару өчен тапшырыла.”.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль
районының Иске Чокалы
авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов